ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» март 2022 ел № 71

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 мартындагы 80 номерлы карары белән расланган «2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына башка бюджетара трансферлар бирү турында» 2022 елның 14 февралендәге һәм 2022 елның 15 февралендәге Башкарма комитеты арасындагы килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 мартындагы 80 номерлы карары белән расланган «2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 «Программа паспортында «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» кисәген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары: | Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан программаны финанслауның гомуми күләме: | | |
|---|---|---|---|
| | ел | җирле бюджет | республика бюджеты |
| | 2021 | 200 мең сум | 122.5 мең сум (спорт җиһазлары);<br>331.4 мең сум (хоккей буенча программаларны тормышка |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | ашыруга) |
| | 2022 | 200 мең сум | 122.03 мең сум (спорт җиһазлары);<br>182.2 мең сум (хоккей буенча программаларны тормышка ашыруга) |
| | Барлыгы | 400 мең сум | 758.13 мең сум |

1.2 “2021-2022 елларга Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү чаралары” 3 кисәгенең 5 бүлегендә 5.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № | Чаралар эчтәлеге | Җашкару срогы | Башкару өчен җаваплы затлар | Финанслау күләме (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 | 2022 |
| 5.6 | Спорт мәктәпләрен җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә бюджетара трансфертлар (республика бюджеты) | 2021-2022 | МБУ «Спорт мәктәбе»; | | 122.5 | 122.03 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**